РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

12/04/2019 № 214

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы**

**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советының 2017 елның 23 мартындагы
№84 "Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Иҗтимагый советы турында нигезләмәне
раслау хакында"карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2014 елның 21 июлендәге 256 – ФЗ номерлы "Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтүләр сыйфатын бәйсез бәяләүне уздыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2005 елның 14 октябрендәге 103 номерлы Татарстан Республикасы Законы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 19 июлендәге 512 номерлы карары белән расланган "2015 - 2021 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру" дәүләт программасы кысаларында, Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү Комиссиясе утырышының 2018 елның 24

сентябрендәге беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2017 елның 23 мартындагы 84 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иҗтимагый советы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Иҗтимагый совет эшчәнлегенең төп максатлары: "түбәндәге эчтәлекле пунктча белән" 2.1 пунктын өстәргә:

“ - Чирмешән муниципаль районында оештырыла торган муниципаль учреждениеләр һәм фондларның ачыклыгын тәэмин итү, җәмәгать контролен тормышка ашыру;"

1.2. 2.2 нче пунктка "Иҗтимагый совет бурычлары булып тора;" түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

“- дәүләт һәм муниципаль программаларны тормышка ашырганда, бюджет акчаларын кулланганда, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алганда җәмәгать контроле;

-дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциягә каршы үз-үзен тотышын формалаштыруга, җәмгыятьтә коррупциягә каршы стандартларны популярлаштыруга һәм иҗтимагый хокукый аңны үстерүгә, җәмәгатьчелекне коррупциягә каршы сәясәткә җәлеп итүгә юнәлдерелгән агарту, белем бирү һәм башка чараларның нәтиҗәлелеген арттыру"

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының интернет челтәрендә рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны торак мәсьәләләре, социаль сәясәт, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм спорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Башлык, муниципаль районы
Советының рәисе Ф.М. Дәүләтшин